# Шигърият белән серләшүче ханымнар

Зәрия **Вәлиева**

Шигърият – гаҗәеп серле дөнья. Хисләр дәрьясы ул, фикер агышы. Һәр өлкәнең үз белгечләре, һөнәрмәндләре булган кебек үк, поэзиянең дә чын-чынлап шигърият өчен туган шәхесләре бар. Гыйлеме, һәм, иң мөһиме, тумыштан – Аллаһ тарафыннан бирелгән таланты булган шагыйрьләр белән янәшә шигырь яратучы, үзе өчен, ягъни күңеле өчен шигырь язучылар да байтак. Профессиональ шагыйрьлеккә дәгъва кылмаучы, тыйнак кына үз даирәсендә, үз дөньясында кайнаучы, вакыт-вакыт күңел дәрьясында ташыган шигъри юлларын газетабызга юллаучы даими авторларыбыз бар. Алар – шигърият серләрен белеп бетермәүләрен дә, иҗатларындагы кайбер чатаклыкларны да, поэзия таләпләренә тулысы белән җавап биреп бетерә алмауларын да аңлыйлар. Әмма шунысы хак, бу шигъри юлларда күңел җылысы, ихласлык бөркелеп тора. Гомер буе авыр физик эш башкарган, гаилә учагын саклаган, иҗатка гашыйк ханымнар хөрмәткә лаек.

Иштирәк сандугачы булган Асия Метшинага да, Новотроицкое авылында яшәүче, поэзияне җаны-тәне белән сөюче Асия Хәсәновага да уртак сыйфат хас – алар шатлык-сөенечләрен, борчу-кайгыларын дөньяга чәчмиләр. Алар – кәгазь-каләм алып, шигърият белән серләшәләр. Ике Асия ханым да – Ана, чын мәгънәсендә баш хәрефтән язарга лаек әниләр. Алар үстергән балалар – илгә-көнгә игелек китерәләр. Димәк, алар ана буларак бурычларын лаеклы башкарганнар. Ә инде шигърияттә алар – үзешчән. Әмма, нәсыйхәтләре – җаныңа үтеп кереп, рухыңны сугарырлык!

Шигъри җанлы Асия ханымнарга сәламәтлек, балалар игелеге телибез. Илһам дәрьягыз һәрвакыт ташып торсын!



**Туганнарым – асыл хәзинә!**

Зәйтүнә апам – оста бәйли,
Нурия апам – абыстай,
Нажия апам кайтса безгә –
Бакча якка чык та тай.
Ул һәрвакытта да,
Телеңне йотарлык итеп
Пешерә тәмлүшкәләр.
«Керегез, кер, ризык пеште!» – диеп,
Иркәләп-назлап эндәшә.
«Исе тышка ук чыккан!» – диеп,
Елмаеп килеп керәм.
Рәхәтләнеп чәй эчәбез,
Җыелып туганнар белән.
И-й, Раббым, гел әнә шулай
Дус-тату яшәсәк иде!
Сыкранмый, зарланмыйча
Аралашып торсак иде!

**Картаю килә икән ул**

Күзләр җиткән саен,
Кошлар киткән саен,
Күңелкәем кала моңланып.
Картаюым җиткән,
Гомер калды микән?
Шул турыда уйлыйм моңаеп.
Гомер узган инде,
Йөрәк тузган инде.
Тормыш сынауларын узарга
Бер Аллаһтан сорыйм сабырлык.
Ике иңемдәге фәрештәләр
Яза бара яхшы-яманны.
Уң ягымдагысына –
Изгелекне язганына,
Иртә-кичен, туктамыйча
Язарга да язарга язсын!
Диеп телим. Кылам изгелек –
Аллаһ кабул итсен!

**Әнкәем нәсыйхәте**

Матди байлык теләмәде әнкәй,
Кичерсә дә күпме кыенлык.
Иман байлыгы һәм дә
Тел ачкычы тели иде әнкәй
һәммәбезгә, һәрчак.
Иманны саклау,
Аны ныгыту, баету
Булды безнең максат.
Туган телебезне ярату да
Ана сөте белән сеңде.
Оныкларым башлый
Эшләрен «Бисмилләһ!» белән
Алар сөйли, көйли
Үз ана телебездә.
Нәсыйхәте әнкәемнең
Һәрвакыт күңелемнең
Тора иң-иң түрендә.

**Без – кунакчыл халык!**

Кунак-төшем – борынгыдан килә
Табыннар мул, сүз бир – җырга-моңга!
Тансыклаган кунак көткән кебек
Бәйрәм кергән авыл өйләренә.

Гел моңаеп яшәмәгән халкым –
Бәйрәм иткән язын, җәен,
Мул уңышлы көзен һәм дә
Сугым мәле – кышларын.

Кучтәнәчсез бәйрәм була алмый –
Табыннарга килә затлы ризыклар:
Чәк-чәк, бәлеш, гөбәдия, бавырсак...
Һич кенә дә санап бетерәм димә.

Җан җылысын дус-туганнар
Якты чырай, күңел иркенлеге
Милли моңнар,җыр-бию һәм
Кучтәнәчләр белән өләшкән.

Табыннарда халкым минем
Кошлар булып сайрашкан.
Хәмерсез дә матур итеп
Табындашлар булып утырган.

Үткәннәрнең матур гадәтләрен
Авылым саклый бүген дә,
Бәйрәм гөрли авыл өендә,
Кучтәнәчләр тәме – телемдә!

**Асия Метшина, Иштирәк авылы.**

**Бишек җыры**

Йокла балам, күз нурым,
Йокласаң, зур үсәрсең,
Мин көйләгән бишек җырын
Бәлки әле отарсың.
Бишекләрдән төшәрсең,
Үсеп буйга җитәрсең,
Зур дәрьялар кичәрсең,
Күп җирләрне гизәрсең.
Бәлки җырчы булырсың,
Табиб, мөгаллим, төзүче...
Һөнәрләр күп җир йөзендә
Кайсын гына сайласаң да,
Кем булсаң да, син – балам –
Илгә кирәкле булырсың! –
Диеп, бишек җыры көйләдем.
Балама – багалмама
Зур өметләр багъладым.

**«Алмакай» бакчасына**

Ак калада – Яр Чаллыда
«Алмакай» исемле бик матур
Балалар бакчасы бар –
Тартып тора ул үзенә
Әллә инде магниты бар.
Бакча мөдире үзе дә
Тәмле телле, бик күркәм,
Ягымлы итеп, ана телендә
Сәламләп каршы ала.
Бинаның тышы – ап-ак,
Эче – пакъ, иркен, якты,
Һич арттырмый әйтә алам –
Анда әкияти матурлык.
Зәңгәр күлдәй бассейнында
Судагы балыклар төсле.
Балалар рәхәтләнеп йөзә.
Татар теле мөгаллиме
Бирә белем сабыйларга.
Туган телңе бик җентекләп
Өйрәтә балаларга.
Аш-су осталары тәмле итеп
Төрле ризыклар пешерә.
Тәрбиячеләре җитез, уңган
Барысына да өлгерә.
Балаларның сәламәтлеген
Шәфкать туташы кайгырта,
Һәркөн кереп аларның
Сәламәтлеген тикшерә.
Гиппократ антын ул
Һәрвакыт исенә төшерә.
Балалар психологы –
Земфира Әсгатовна. Ул –
Сабыйлар белән аралашып
Әйбәт киңәшләрен бирә.
Җыештыручы бик пөхтә –
Бар җирне тәртиптә тота.
Бакча мөдире барысына да
Дөрес юнәлеш биреп тора.
Балаларның шат авазы
Бакчаны ямьгә төрә.
Мактадым әле бакчаны
Күкләргә чөя-чөя,
Үзе матур, үзе яхшы
Гөлбакча дия-дия.

**Татарстаныма**

Республикамда төрле милләт яши
Дус-тату гаилә сыман гөрләшеп.
Очрашканда бертуганнар сыман
Сүзләр бетми, сөйләшеп.

Дуслык, бердәмлек – зур байлык,
Дус-тату булуга, дуслар, ни җитә?!
Бердәмлектә – көч, без – беләбез,
Тыныч-имин бул, Татарстаным гомергә!

Басу-кырларың, урман, су буйларың –
Ямьнәр өсти хәзинә тулы җиремә.
Чит җирләрнең алтын тавына да
Алыштырмам туган илемне.

Туып-үстем Татарстанымның
Оҗмахка тиң матур җирендә.
Горурланып олы бәйрәм көнне
Рәхмәт әйтәм сиңа бүген дә.

Шушы матур, ямьле җәй көнендә
Татарстан – олы бәйрәмең.
Күп милләтләрне сыйдырасың
Кыйблаң – туры, күңелең киң синең.

**Асия Хәсәнова,
Новотроицкое авылы.**